КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Мамалай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17.09.2022 № 5

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып, «Сез 2023 нче елда Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Мамалай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2800 (ике мең сигез йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Мамалай авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, ком нигезен урнаштру,вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сүүткәргеч торбаларны җиһазлау,килөшү буенча эшләр өчен түләү);
- Мамалай авылының күмү урыннарын һәм янәшәсендәге территорияне карап тоту;
- Мамалай авылында Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә һәйкәл төзү һәм якындагы территорияне төзекләндерү, дигән сорау буенча 2022 елның 17 сентябендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына <u>146</u> кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны <u>82</u> кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан <u>82</u> кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы <u>0</u> тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Мамалай торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2023 нче елда Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Мамалай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2800 (ике мең сигез йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Мамалай авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, ком нигезен урнаштру,вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сүүткәргеч торбаларны җиһазлау,килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) Мамалай авылының күмү урыннарын һәм янәшәсендәге территорияне карап тоту;
3) Мамалай авылында Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә һәйкәл төзү һәм якындагы территорияне төзекләндерү, карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Сатыш авыл
җирлеге башлыгы

Ф.Ф.Шафигуллин